| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН СОВЕТ<br>АКСУНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>АКСУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

«30» декабрь 2021 ел № 36-1

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлеге муниципаль берәмлеге тарафыннан Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәрен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлеге Советының 2020 елның 27 маендагы 89-1 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлеге җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен бирү (кабул итү) турында Буа муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән килешүләр төзү тәртибе нигезендә Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлеге советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлеге Советының 2013 елның 11 февралендәге 1-29 номерлы «Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре турында» карары белән расланган Аксу авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү өлешендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы тәкъдимен кабул итәргә (21.09.2016 № 18-1, 23.09.2017 № 36-1, 11.02.2019 № 65-1, 23.06.2021 № 24-1 карарлары редакциясендә).

2. Аксу авыл җирлеге Советына Буа муниципаль районы Советы белән Буа муниципаль районы бюджетыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Аксу авыл җирлеге бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында килешү төзергә.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә кайтарам.

Буа муниципаль районының
Аксу авыл җирлеге башлыгы М.М. Хәйретдинов